# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең Сармаш-Баш торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**29.11.2022 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 29 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

*«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең Сармаш-Баш торак пунктында узган җыен нәтиҗәләре турында 2022 елның 15 ноябрендәге 02 номерлы карарда техник хата җибәрелү белән бәйле рәвештә, әлеге карарның 2, 3 абзацларын яңа редакциядә укырга:*

*«Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:*

*сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 190 граждан кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 104 кеше.*

*Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:*

*гражданнар җыенында катнашучыларның 104се “Риза” позициясе өчен тавыш бирде;*

*гражданнар җыенында катнашучыларның 0 “Каршы” позициясе өчен тавыш бирде».*

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 190 граждан кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 103 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

« Риза » позициясе өчен 103 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең Сармаш-Баш торак пунктында гражданнар җыенын узган һәм гражданнар җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны

*«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең Сармаш-Баш торак пунктында узган җыен нәтиҗәләре турында 2022 елның 15 ноябрендәге 02 номерлы карарда техник хата җибәрелү белән бәйле рәвештә, әлеге карарның 2, 3 абзацларын яңа редакциядә укырга:*

*«Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:*

*сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 190 граждан кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 104 кеше.*

*Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:*

*гражданнар җыенында катнашучыларның 104се " Риза " позициясе өчен тавыш бирде;*

*гражданнар җыенында катнашучыларның 0 " Каршы " позициясе өчен тавыш бирде»* **кабул ителгән** дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен 7 көн эчендә (Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставының 69ст. 5п.) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Сармаш-Баш торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш
авыл җирлеге башлыгы ____________ Р.М.Фәсхетдинов
(имза)